РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
СТАРОЧЕЛНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423004, с. Старые Челны, ул. Ленина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧАЛЛЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
423004, Иске Чаллы авылы, Ленина ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Чаллы ав. КАРАР

«02» ноябрь 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 18 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Гагарин, Яшьләр һәм Үзәк урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 18 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Болын һәм Елга арьягы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылы Кыр урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2021 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Чапаев, Ленин һәм Мәктәп тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Түбән Чаллы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлыгы булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Түбән Чаллы торак пунктының су системасы коеларын һәм янгын гидрантларын төзекләндерү белән алыштыру;

- Түбән Чаллы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау:

« РИЗА» «КАРШЫ» ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Түбән Чаллы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров